*Г.Р.Хисматуллина*
*I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы,*
*2нче номерлы Биектау урта мәктәбе, Биектау районы*

# СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАР БЕЛӘН ЭШ

Укыту-тәрбия эшенtең уңышы укытучының, сыйныф җитәкчесенең бу процессны сыйфатлы башкаруында, укучыларны танып-белү процессы белән кызыксындыра алуында; иҗади уйларга, мөстәкыйль белем алырга өйрәтүенә, рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләвенә бәйле. Әйләнә-тирәне, кешелек дөньясын өйрәнү һәм аны укучыга дөрес аңлату, укучыны тормышка яраклаштыру – укытучылар алдына куелган мөһим бурыч.

Укытучының төп максаты - укыту-тәрбия бирү процессында укучының белем алуга сәләтен ачу, универсаль уку гамәлләре формалаштыру, рухи яктан камил, иҗади мөмкинлекләрен тормышка ашырырга сәләтле, гомумкешелек кыйммәтләренә ия шәхес тәрбияләү.Сәләтле балалар белән эшләү укытучы эшчәнлегенең иң мөһим юнәлешләренең берсе булып тора. Сәләтле балалар белән эшләүнең төп максаты - һәр укучының сәләтен ачу, иҗади башлангычын үстерү. Мондый укучылар белән эшләгәндә эзләнергә, яңа мөмкинлекләрдән файдаланырга кирәк. Сәләтле балалар белән эшнең башы - укучыда теләк уяту. Халыкның әдәбиятын, әдәбият аша мәдәниятен өйрәтү, гореф-гадәтләренә, тарихына карата кызыксыну уяту. Кызыксыну уятып кына калмыйча, класстан тыш чаралар ярдәмендә шундый ук мохит, шул тирәлектә яшәү ихтыяҗы тудыру.

Үткәрелгән чараларыбыз да милли тәрбия үсешенә омтылып башкарыла. Бу максаттан һәрберебез вакытлы матбугатны, радио-телевидение тапшыруларын, килгән киноспектакльләрне карау һәм әңгәмә оештыру кебек чараларны куллана. Төрле яшьтәге укучылар белән үткәрелгән һәм ел саен кабатлана торган “Каз өмәсе”,”Татарча чыршы бәйрәме”, “Сөмбелә”, “Әбиемнең сандыгы”, “Нәүрүз”, “Аулак өй”, “Озын толым” һ.б. чаралар нәкъ менә милли гореф-гадәтләребезгә нигезләнеп, алардагы нәфислекне, күңел сафлыгын, әдәп –тәрбия дәрәҗәсен аңлату, кире кайтару максаты белән эшләнә.

Бу чараларга балалар бик теләп катнашалар. Хәзер китап, газета-журнал уку үзенең актуальлеген югалтып бара, чөнки мәгълүмат чаралары бик күп, аларның байтагы җиңел генә күп мәгълүмат табарга мөмкинлек бирә. Безне нәрсәгә өндиләр – яңа технология, компьтер технологиясенә. Мин, шәхсән, күңел технологиясе, шәхес үстерү технологиясе яклы. Яңа чаралар – заман таләбе, алар бик кирәкле һәм уңайлы, ләкин китап уку баланы мәгълүмат белән генә баетмый, хис-тойгы байлыгы да бирә. Мин укучыларыма шул фикерне сеңдерергә тырышам  Авторлар, язучы, шагыйрьләр белән мәктәптә очрашулар үткәргәндә, китапларга автографлар куйдырып авторның үзеннән алган китап баланы битараф калдырмый. Мәктәп программвсындагы әсәрләрне укымыйлар инде. Мөмкинлек булганда спектакльгә барырга тырышабыз.”Галиябану”, “Сүнгән йолдызлар”, “Гашыйклар тавы” һ.б. узган ел “Ак чәчәкләр” киносын дәрестән сон калып карадык. Сәләтле балалар белән эшләү программасына олимпиадаларга әзерләнүне генә түгел, ә тәрбияви чараларда катнашуны да кертү мөһим.Тотрыклы (толерант) шәхес тәрбияләү – ул укучыларда башка милләт кешеләренә, аларның мәдәниятенә уңай мөнәсәбәт булдыру дигән сүз. Без балаларда үз халкыбызга, үз илебезгә мәхәббәт тәрбияләү белән генә чикләнмичә, кайда яшәүләренә һәм нинди милләт кешеләре булуга карамастан – барлык халыкларны, аларның мәдәниятен, гореф-гадәт, традицияләрен хөрмәт итәргә, табигатьне яратырга өйрәтәбез, гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштырабыз. Үз мәдәниятләре белән беррәттән,  башка халыкларның да мәдәниятен, телен белергә тиеш.

Узган ел без ике тапкыр Тыва Республикасы белән онлайн элемтәгә чыктык. Чит төбәкләрдә яшәүче укучылар белән турыдан-туры  аралашу балаларга бик ошады.  Беренче очрашуда 6  мәктәп катнашты:  Татарстан, Мәскәү, Яр,     Осетия, Тыва республикалары укучылары үзләренең туган телләре турында сөйләделәр. Без татар халкының тарихы белән таныштырдык, җырлар җырладык, шигырьләр сөйләдек. Соңыннан һәр милләт укучылары үз телләрендә 5әр сүз өйрәттеләр. Һәрберсе кабатлады. Икенче очрашуыбызда татар халкының милли йолалары белән таныштырдык. “Аулак өй” күренешен

күрсәттек. Сонынннан “Мин яратам сине Татарстан” җыры белән тәмамладык. Алар безгә үз халкы йолалары турында сөйләделәр. Балалар бер-берсенә сораулар бирделәр. Бу бик җанлы аралашу булды.Мондый чаралар балаларда милли горурлык хисе тәрбияли. Мондый чараларда сәләтле балаларга ияреп башка укучылар да тартылалар.

Сәләтле укучыларым татар теле олимпиадаларында актив катнашып киләләр. Берничә ел рәттән югары күрсәткечләргә ирешеп, республика турында призер булдылар.

Балаларда милли мәдәният турында өрбөтен күзаллау булдыру – туган телеңне белү һәм шул телдә аралашу; халык авыз иҗатын – экиятләр, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар, бишек җырларын белү; шигырьләр, җырлар өйрәнү; халыкка хас әдәп кагыйдәләрен, туган як табигатен, милли халык уеннарын белү дигән сүз.

Яшь буынга дөрес тәрбия бирү вазыйфасына һәр ата-ана җитди һәм җаваплы карарга тиеш. Ә моңа тиешле педагогик белем алу, тәрбия бирү чараларын белү, үтәү нәтиҗәсендә генә ирешергә мөмкин. Ә мәктәп менә шул зур вазифаны башкара ала. Бу юнәлештә Р.Фәхреддин хезмәтләрен файдаланып, түбәндәге темаларга ата-аналар җыелышлары, кичәләр һ.б. үткәрәм.

Сүземне педагог-галим В.Казыйхановның сүзләре белән йомгаклыйсым килә. “ Әгәр укытучы-тәрбияче белән бала өчпочмакның ике ягын тәшкил итсә, өченче – таянып торган ягы - ата-ана”. Мин аның бу фикере белән тулысынча килешәм. Кеше гамәлләренең әхлакый сыйфатларына бик яшьли нигез салына. Гаделлек, хезмәт сөючәнлек, кыюлык кебек уңай сыйфатлар яшьтән үк әхлакый гадәтләр буларак тәрбияләнгәндә генә, кешенең гомерлек ышанычлы юлдашына әйләнәчәк. Бала кечкенәдән үк үз-үзенә хезмәт күрсәтү һәм билгеле бер режимны үтәү бурычларын, нәрсәне эшләргә ярый, нәрсәне ярамый икәнлеген белергә тиеш. Мин дә әлеге өчпочмакның 3 ноктасы арасындагы бәйләнешне саклап эшләргә тырышам.